| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Брюшлинского сельского поселения Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге советы |

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ<br>2022 елның 25 апреленнән | К А Р А Р<br>№51 |

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга «"Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259 номерлы Федераль законга, "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 1 апрелендәге 90 номерлы Федераль законга нигезләнеп, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бөрешле авыл җирлеге»ндә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2015 елның 26 февралендәге 153 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә

1.1. Нигезләмәнең 6 пунктындагы пунктчада «акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга;

1.2. Нигезләмәнең 6 пунктындагы пунктчада «оешмалары» сүзеннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә;

1.3. Нигезләмәнең 13 пунктында «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

1.4. Нигезләмәнең 13 пунктында «оешмалар» сүзеннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә www.mendeleevsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

Бөрешле авыл җирлеге Советы рәисе Л.А.Смирнова